**Казан шәһәр Думасының 2024 елның 28 августындагы**
**6-32 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә урам-юл челтәренең (УДС) ярдәмче зонасы чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 43 статьясы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 28 мартындагы 1172 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә территориаль зоналар: урам-юл челтәре (УДС), табигый-рекреацион комплекс (ПРК), махсус билгеләнештәге яшелләндерү (ОСН), яр буе территорияләре (ТТ) ярдәмче зоналарын чагылдырып, шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында урам-юл челтәренең (УДС) ярдәмче зонасы чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында Казан шәһәр Думасы карары проектын әзерләү хакында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 30 октябрендәге 1027 номерлы «Шәһәр төзелеше эшчәнлегенең махсус режимы булган махсус сакланылучы табигать территориясен урнаштыру чикләрен билгеләү максатларында «Казансу елгасының сул як яры» территориясен (Миллениум күперennән 3 нче транспорт дамбасына кадәр) планлаштыру проектын раслау турында» карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 18 февралендәге 160 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) нигезендә һәм 2024 елның 11 июленнән 2024 елның 25 июленә кадәр уздырылган иҗтимагый фикер алышуларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәр Думасы **карар чыгарды**:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә Казан шәһәр Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигый-рекреацион комплекс, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында: территориаль зоналар – табигатьне саклау, рекреация һәм башка кыйммәтле әһәмияттәге махсус зонасының (Р0) (22 номерлы контур), транспорт объектларын урнаштыру зонасының (Т) (9 номерлы контур), рекреация зонасының (Р2) (37 номерлы контур, 24 номерлы контур, 35 номерлы контур), иҗтимагый-эшлекле


билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасының (ОД) (2 номерлы контур, 6 номерлы контур), урта катлы торак төзелеше зонасының (Ж3) (8 номерлы контур), күпкатлы торак төзелеше зонасының (Ж4) (10 номерлы контур, 17 номерлы контур), индивидуаль һәм блоктан торак төзелеше зонасының (Ж1) (30 номерлы контур), катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасының (ОЖ) (18 номерлы контур) урам-юл челтәре (УДС) зонасы чикләрен үзгәртергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru).

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәр Думасының <u>2024</u>
<u>елның 28 августындагы 6-32</u>
номерлы карарына кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигый-рекреацион комплекс, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре чагылдырылган шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**ОД - 6**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төре исеме** |
|---|---|---|
| | Ж3 | Урта катлы торак төзелеше зонасы |
| | Ж4 | Күпкатлы торак төзелеше зонасы |
| | Р0 | Табигатьне саклау, рекреация һәм башка кыйммәтле әһәмияттәге махсус зона |
| | Р2 | Рекреация зонасы |
| | Р1 | Табигый территорияләр зонасы |
| | Т | Транспорт объектларын урнаштыру зонасы |
| | ОД | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы |
| | ОЖ | Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы |
| | Ж1А | Күпфатирлы төзелеш чикләрендә индивидуаль торак төзелеше зонасы |
| | Ж1 | Индивидуаль һәм блоктан торак төзелеше зонасы |

**Территориаль зоналарның ярдәмче зоналары**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зонаның ярдәмче зонасы төре исеме** |
|---|---|---|
| | УДС | Урам-юл челтәре зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигый-рекреацион комплекс, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре чагылдырылган шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты чиге |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**